Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы

КАРАР № 2-2

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 11 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 2014 елның октябрендәге “Җир салымы турында” 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 29 сентябрендәге “Россия Федерацисе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында” 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 18 октябрендәге 9 номерлы “Җир салымы турында” гы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 2015 елның 15 июнендәге 13 номерлы, 2015 елның 15 октябрендәге 4 номерлы, 2018 елның 30 октябрендәге 15 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 17 номерлы, 2019 елның 20 июндәге 3-2 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән гайре) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән гайре) җир кишәрлекләренә карата -0,3%”

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru, веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында

һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башлыгы И.Р. Таҗетдинов